وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!


6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№10 (179). 8 март 2013 / 26-рабыгыль-ахир-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ


Исламда хатын-кыз
▷2◁


Мәула Колыйның дини-илаһияти карашлары
▷3◁


ИГЪТИБАР! Мөфти булырга теләүчеләргә куелган таләпләр
▷4◁

# Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә кадрлар үзгәреше

**6 март көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленум утырышы үткәрелде. Анда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәйзов сәламәтлегенә бәйле сәбәпле отставкага китүен белдерде. Шулай ук мөфтинең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әднәмов та үз вазифасыннан китте. Бертавыштан кабул ителгән карар нигезендә, вакытлыча мөфти вазыйфаларын башкару мөфтинең фәнни эшләр буенча урынбасары Камил хәзрәт Сәмигуллинга йөкләнде.**



**Сәмигуллин Камил Искәндәр улы турында БЕЛЕШМӘ.**
*1985 елның 22 мартында туган.*
**Дини белеме:**
*2003 ел - Төньяк Кавказ ислам университетында белем ала (Махачкала шәһәре);*
*2004-2007 еллар - Истанбул шәһәре мәдрәсәсендә укып, фикъһе, фикъһе ысулы, гакыйдә, хәдис, хәдис ысулы, хөснел хат, сарыф (морфология) һәм нәһү (грамматика) буенча иснәд (Пәйгамбәребездән (сгв) башлап Әбу Хәнифә аша өзелми килгән чылбыр) белән иҗазәт (шәригать фәннәрен укыту өчен рөхсәт) ала. Шулай ук 6 ышанычлы хәдис җыентыгыннан белем бирү өчен шәех Габдерәхим Сәет Ликрим бине Нәхилдән (Марокко) алган иҗазәте бар;*
*2013 ел - Россия ислам институты ислам фәннәре факультетының соңгы курсында укый.*
**Эш урыны:**
*2008 ел - Казан шәһәренең Мирный бистәсендәге Тынычлык мәчете имам-хатыйбы итеп сайлана;*
*2011 елдан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең нәшрият бүлеген җитәкли.*
**Башкарган вазифалары:** *фәнни эшләр буенча мөфти урынбасары, нәзарәтнең Президиум әгъзасы. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы, Татарстан Республикасының баш казые киңәшчесе, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Экспертлар советы җитәкчесе.*
*Гарәп һәм төрек телләрендә иркен аралаша.*
*Өйләнгән, 3 баласы бар.*

**Чыганак: www.dumrt.ru**

# РУХИ МАТУРЛЫК ҺӘМ ТЫШКЫ МАТУРЛЫК

**Әхлакый һәм эстетик якларны бергә бәйләү Ислам турындагы карашларның бербөтенлеген билгели.**

Рус классикларының берсе шулай дип язып калдырган: "Кешедә барысы да гүзәл булырга тиеш: йөзе дә, киеме дә, күңеле дә, уйлары да". Бу гыйбарәнең мөһимлеге бүгенге көндә дә үзен яхшы сиздерә. Моның аеруча Исламда тулысынча чагылыш табуын күрә алабыз. Чөнки Ислам кешенең эчке күңел халәте: аның гөнаһлы уйлардан арынуын кайгыртуны гына түгел, ә бәлки тәнеңнең дә, киемнәреңнең дә чиста һәм пөхтә булуын таләп итә торган дин. "Аллаһ гүзәл һәм гүзәллекне ярата", - диелә хәдистә.

Ләкин кайвакыт кешенең бу ике максаты - рухи матурлыкка һәм тышкы матурлыкка омтылышы үзара ярашып, үсеп китә алмый, бер-берсенә каршы килә башлый. Кайберәүләр рухи матурлыкны - күркәм холыкны һәм игелекле



ниятләрне югары баскычка куеп, тышкы кыяфәт ул кадәр үк мөһим түгел дип исәпләргә дә мөмкин. Алар ни рәвешле киенеп йөрүләренә, нинди кыяфәттә булуларына артык әһәмият бирмиләр, бу турыда еш кына оныталар, үз-үзләрен кайгыртмыйлар. Икенчеләре исә, киресенчә, үзләренең тышкы кыяфәтләре хакында артык нык уйланалар, үзләрен төрле зиннәтле әйберләр, затлы "кием"нәр белән бизәргә тырышалар. Шулай итеп, алар тышкы кыяфәтләрен табыну объектына әйләндерәләр, ә үзләренең күңел халәтләре турында, гомумән, оныталар.

Ләкин кешенең матурлыгын билгеләүче бу ике якның төрле табигый төсмергә ия булуын истән чыгармаска кирәк. Алар шуңа күрә дә бер-берсенә каршы куела алмый, чөнки һәрберсе кабатланмас кыйммәткә, үзмәгънәгә ия. Әгәр дә рухи матурлык кешеләрдә сыйфатка ия өстенлекләр барлыкка китерә, аның холкын яхшырта, анда сабырлык һәм тыйнаклык кебек сыйфатлар тәрбияли икән, тышкы кыяфәт исә гамәли әһәмияткә ия. Пөхтә, чиста һәм матур итеп киенеп йөргән мөселман кешесе тирә-юньдәгеләргә үзе турында гына түгел, ә бар ислам дине турында да уңай образ тудырырга һәм яхшы тәэсир калдырырга сәләтле. Нәкъ менә әхлакый һәм эстетик якларны берләштерү Ислам турында бербөтен карашларны билгели дә инде. Моңа охшаш дәлилләрне Әбел-Әхвас әл-Җашами аша тапшырылган хәдисләрнең берсендә табарга була: "Бервакыт Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!) мине иске сәләмә киемнәрдә күреп, минем матди хәлемнең ничек булуы турында сорады. Мин үземнең яхшы ук хәлле кеше булуым турында әйттем. "Ә синең нинди бай-

*(Ахыры 2,4 нче битләрдә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАМИЛ ХӘЗРӘТ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**6 март көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти вазифаларын вакытлыча башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин журналистлар белән очрашу үткәрде.**

Камил хәзрәт, сорауларга җавап биреп: "Бүген Диния нәзарәтендә Пленум утырышы үткәрелде. Менә шушы утырышта миңа вакытлыча Татарстан мөфтие вазифалары йөкләнде. Киләсе, чираттан тыш Корылтайга һәм яңа мөфти сайланганчыга кадәр Татарстан мөфтие вазифаларын вакытлыча мин башкарып торачакмын. Бүгенге көндә безнең төп бурыч - Диния нәзарәтенең эшчәнлеген яхшы дәвам итү, өммәтебезнең тынычлыгын, бердәмлеген саклау һәм корылтайга тиешенчә әзерләнеп, аны яхшы итеп уздыру", - диде.

Шулай ук очрашуда Мөфти булырга теләүчеләр 14 мартка кадәр Диния нәзарәтенә гаризаларын тапшыра алулары хакында әйтелде. (Газетабызның 4 нче битенә игътибар итегез.)

Президиум кандидатларның документларын тикшерәчәк. 16 март көнне тагын бер кат чираттан тыш Пленум утырышы уздырылачак. Анда рәсми кандидатлар игълан ителер һәм чираттан тыш корылтай көне билгеләнер дип көтелә. Корылтайда исә мөфти сайланачак.

### КАЛЛИГРАФИЯ КОНКУРСЫНА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

**14 март көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте гарәп каллиграфиясе буенча конкурс үткәрәчәк.** Чарада катнашучыларның эшен танылган каллиграф Нәҗип Нәккаш һәм Россия ислам институтындагы каллиграфия үзәге директоры Рамил Насыйбуллов бәяләячәк.

Конкурсның үткәрелү урыны итеп Халыклар дуслыгы йорты (Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 57 нче йорт) билгеләнгән. Ул каллиграфия сәнгатен һәм гарәпчә язу мәдәниятен популярлаштыру максатыннан оештырыла.

Конкурс өч өлештән торачак. Беренчесе - төрле язу төрләре белән эш итү, икенчесе - ирекле каллиграфия композициясен тудыру, өченчесе - каллиграфия композицияләрен уку. Конкурста шулай ук алдан җибәрелгән эшләр дә каралачак. Ахырдан танылган каллиграфлар мастер-класслар үткәрәчәк.

### СТУДЕНТЛАРГА - КИТАП, МОХТАҖЛАРГА - РИЗЫК

**"Зәкят" хәйрия фонды "Гыйлем - яктылык" акциясе кысаларында махсус сумкалар әзерләде.** Фонд эмблемасы төшерелгән әлеге сумкаларга дини китаплар тутырылган. Бу үзенчәлекле сумкалар Казан мәчетләрендә балаларга Коръән өйрәтәчәк студентлар өчен әзерләнгән.

Шулай ук фонд хезмәткәрләре шушы көннәрдә мохтаҗларга ризык тутырылган пакетлар өләште. Фондка мөрәҗәгать итеп тә килә алмаганнарга, хастаханәләрдә ятучыларга пакетлар илтеп бирелде.

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ

**Бүгенге көндә кайсы диндә хатын-кызның хокуклары кимрәк дигән сорау куйсак, һичшиксез, күпчелек кеше: "Ислам динендә", - дип әйтер иде. Моның сәбәбе - ислам дине дошманнарының гасырдан артык мөселман хатыннарының хокуклары бозылуы турында чаң кагуларында. Ә без, кайчандыр көчле булган һәм алдынгы урында торган мөселманнар, бүгенге көндә шуларның ихтыярына буйсынабыз. Көчләп тагылган фикерләр белән эш итүебез аркасында Аллаһы Тәгалә биргән көчкодрәтебезне югалттык та инде. Көндәлек тормышыбызда дин күрсәтмәләрен үтәмибез. Тормышыбыз, гаиләләребез Көнбатыш илләре үрнәгендә көйләнгән.**



Ислам динен гаепләргә җыенган кеше башка халыклардагы һәм башка диннәрдәге хатын-кызларның тормышлары белән дә кызыксынып карасын иде. Византиядә дә, Иранда да, Һиндстан белән Кытайда да, яһүдиләрдә һәм христианнарда да, ислам динен кабул иткәнче яшәгән гарәпләрдә дә хатын-кызларның хәле яхшылардан булмаган. Тарих фәненнән язылган китапларны укып карасагыз, хатын-кызларның бернинди дә хокуклары булмавын күрерсез. Ислам дине килгәнче хатын-кызлар күпме кимсетелүләргә дучар булган!

Мәсәлән, ислам динен кабул иткәнче, гарәпләр ярлылыктан һәм хурлыктан куркып, яңа туган кыз балаларны тере килеш күмә торган булганнар. Коръәни-Кәримдә бу турыда болай диелә: "Аларның берәрсенә:

- Хатының кыз бала тапты, - дип, сөенечле хәбәр китерсәң, үпкәләүдән аның йөзе карала. Бу хәбәрне алгач, ул кардәшләренең күзенә күренергә оялып, качып йөри:

- Моны (кыз баланы) мескен рәвештә янымда асрыйммы, әллә туфракка күмимме? - дип хәсрәткә бата. Гыйбрәт алыгыз: бу нинди яман гамәл" ("Нәхел (Бал корты)" сүрәсенең 58-59 нчы аятьләре).

Ислам дине килү белән, хатын-кызларның хокуклары барлыкка килә. Аңа хөрмәт белән карый башлыйлар. Ислам динендә ана хокуклары ата кеше хокукларыннан өстенрәк була башлый. Моны Әбу Һөрәйрә китергән хәдис тә дәлилли. "Аллаһның Рәсүленә (сгв) берәү килгән дә:

- Ий Аллаһның Рәсүле, минем тарафтан яхшы мөгамәлә өчен иң лаеклысы кем? - дип сораган.

Ул әйткән:

- Синең әниең.

Аннан соң бу кеше тагын сорау биргән:

- Ә аннан кала кем?

Рәсүлебез (сгв):

- Синең әниең, - дигән.

Бу кеше кабат:

- Ә аннан соң кем? - дигән.

Ул тагын:

- Синең әниең, - дип җавап кайтарган.

Бу кеше янә бер тапкыр:

- Ә аннан соң кем? - дип сораган.

Шуннан соң Пәйгамбәребез (сгв) аңа:

- Синең әтиең, - дигән".

Ислам дине килү белән "хатын-кыз" сүзе горурлык белән әйтелә башлаган, чөнки бу атама белән Коръәни-Кәримдәге сүрәләрнең берсе аталып йөртелә. (Сүз Һиҗрәттән соң Мәдинәдә иңгән "Ән-Ниса", ягъни "Хатыннар" сүрәсе турында бара. Бу сүрәдә хатыннар турында, җәмгыять эчендә аларның хаклары, иҗтимагый мәйдандагы тоткан урыннары турында сөйләнә. - ред.) Аллаһы Тәгалә дине хатын-кызларга мирас калдыру хокукы бирә һәм шулай ук хатын-кыз милкен кагылгысыз итә.

Бу - ислам дине хатын-кызларга биргән хокукларның берничәсе генә.

Феминистик оешмалар хатын-кызларга азатлык бирүне таләп итә, ә без андый азатлыкның хатын-кызга зарар китерүен күрәбез, чөнки чиксез азатлык беркемгә дә яхшылык китерми. Ул азатлык азат хатын-кызларга нәрсә бирә соң? Тәннәре белән сату итүнеме? Хәмер эчемлекләр эчүнеме? Наркоманиянеме? Теләсә кем белән җенси мөнәсәбәтләргә керә алунымы? Нәрсәгә кирәк мондый зат? Кемгә кирәк мондый азатлык? Бу "азат" хатын-кызның матурлыгы кемгә кирәк? Ә картайгач, ул үзе генә кемгә кирәк булачак? Ул картлык көннәрен ялгыз кичерә, ә балалары аның янына елга бер-ике мәртәбә генә килеп хәлен белә башласа яки бөтенләй ташласа?

Хөрмәтле хатын-кызлар, уйланыгыз! Бу хатын ислам дине биргән ирекне сайлап, уйдырмалы азатлыктан баш кага. Ул миллионнарча хатын-кыз үзендә таба алмаганны табуы белән бәхетле.

Ир-ат таштан яисә кирпечтән йорт салса, бу йорт - бу дөньяның бәрәкәте, ә йортка турылыклы хатын-кыз биргән ямь, җылылык һәм тәрбия бу һәм киләчәк дөнья өчен бәрәкәт булып тора.

Йорт - мөселман кеше өчен ныгытма. Әгәр дә бу ныгытманы төзүдә хатын-кыз катнашмаса, анда бәрәкәт булмый. Аллаһы Тәгаләне зекер иткән, ислам динен өйрәнгән, турылыклы мөселманнар тәрбияләгән гаиләләр бәхетле.

Ана - батырларны, галимнәрне һәм тәкъва кешеләрне тәрбияләп үстерүче зат. Безне чын тормыш белән таныштыручылар - күркәм холыклы, дини, белемле, сабыр, дога кылучы, гафу сораучы әниләребез.

Мондый хатын-кызларның берсе белән Мөхәммәд пәйгамбәр булганчы да, пәйгамбәр булгач та ризалыкта тигез тормыш кичергән. Хәдичә - беренчеләрдән булып: ислам динен кабул итүче, Пәйгамбәребез (сгв) белән намаз укучы, җәннәт белән шатландырылучы, Коръән сүзләрен ишетүче. Аны Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша сәламли. Ул үзенең милкен Аллаһы Тәгалә юлына тота. Пәйгамбәребезне (сгв) кешеләр кире каккач та, ул аңа ышана, ялганда гаепләгәч - хаклыгын раслый, ярдәмсез калдыргач - ярдәм итә. Һәм Аллаһы Тәгалә аларны балалар белән шатландыра.

Пәйгамбәребезнең (сгв) Хәдичәдән туган кызы Фатыйма, Хәсән белән Хөсәеннең әнисе, Гали хатыны - бөтен хатын-кыз һәм барлык аналар өчен үрнәк булып тора.

Гайсә пәйгамбәрнең әнисе - Мәрьямнең диндарлыгы хакында Коръәни-Кәримнең күп кенә аятьләрендә әйтелә. Аның исеме белән Коръәни-Кәримдәге бер сүрә дә атала.

Фиргәвен хатыны Асия дә, иренең ышанмавына карамастан, Аллаһы Тәгаләгә ышана. Ул Муса галәйһиссәламне тәрбияли.

Бөек галимнәр, укытучылар тормышын өйрәнсәк, аларның галим булуларында яшьтән үк белем алырга өндәгән әниләренең өлеше зур. Мисал итеп, Әбу Хәнифәне, имам Шәфигыйне китерергә була.

Уйланыгыз! Хатын-кызларга аеруча ихтирам күрсәтелә башлау ислам дине белән бәйле түгелме соң? Ирләре хатыннарын саклап кына торырдай энҗе бертеге дип атамыйлармы? Мондый хөрмәт Аллаһы Тәгаләгә буйсынган, Аның күрсәтмәләрен башкарган һәм тыйганнарыннан тыелган хатын-кызларга гына насыйп була. Ир-атларның дүрт кешегә карата бурычлары бар: әнигә, хәләл җефеткә, сеңелләргә һәм кыз балаларга. Аллаһы Тәгалә бездән аларның һәрберсе турында сораячак. Без аларның хокукларын саклаганбызмы? Әниебезнең сүзен тыңлаганбызмы, аңа карата яхшы теләктә булганбызмы, шатландырырга тырышканбызмы? Сеңелебезне яклаганбызмы, хәләл җефетебезгә карата гадел булганбызмы, кыз балабызга дөрес тәрбия биргәнбезме?

Бүген бөтен дөнья 8 Март бәйрәмен - Халыкара хатын-кызлар көнен билгеләп үтә. Бу бәйрәмнең килеп чыгышы турында төрле юрамалар йөри. Безнең өчен кадерле булган хатын-кызларыбызны елга бер тапкыр гына, уйлап чыгарылган бәйрәмне сәбәп итеп, игътибар күрсәтеп, үпкәләтәсе килми. Бу бәйрәмне оештыручыларга сәбәп кирәк булса, мөселман кешесенә хатын-кызлар өчен көн саен бәйрәм оештырырга кирәк. Әгәр дә без әдәпле һәм әниләребезгә карата ихтирамлы булсак, аларга ярдәм итәргә һәм аларны шатландырырга тырышсак, бу бәйрәм алар өчен түгелме соң? Сеңелебезгә шалтыратып, хәлләрен белешеп, кунакка барып йөрсәк, сеңелкәшебез өчен бу бәйрәм булмыймы соң? Хатыннарыбызга карата гадел булсак, йомшак сүзләр кулланып сөйләшсәк, ягымлы һәм игътибарлы булсак, бу алар өчен бәйрәм булмыймы соң? Кызыбызны яхшы гореф-гадәтләрдә йомшак холыклы итеп тәрбияләсәк, бу аның өчен шатлык булмыймы соң?

Әйе, кардәшләр, бу чынлыкта да шулай. Әгәр дә без, ир-атлар, хатын-кызларыбызның һәрберсе өчен тиешле гамәлләр кылсак, гаилә бәйләнешләре нык булачак, ә моның белән бергә без яшәгән җәмгыять тә яхшы якка үсәчәк.

Вәгаземне тәмамлап, сезгә Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен исегезгә төшерәсем килә: "Әй, барча инсаннар! Сезне бер җаннан яралткан вә аңа хатынны бар иткән, аларның икесеннән ир җенес вә хатын җенесен үрчеткән Раббы (каршында гөнаһ кылудан) куркыгыз. Исемен теләкләрегездә куллана торган Аллаһ алдында гаепле булудан һәм кардәшлек җепләрен өзүдән сакланыгыз. Шик-шөбһәсез ки, Аллаһ сезне күзәтеп торучыдыр" ("Ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 1 нче аяте).

# РУХИ МАТУРЛЫК ҺӘМ ТЫШКЫ МАТУРЛЫК



***(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)***

лыкларың бар соң?" - дип сорады ул. Мин: "Аллаһның рәхмәте белән миндә дөяләр һәм сарыклар бар", - дип җиткердем Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде!). "Ул вакытта Раббыбызның биргән мул бүләкләрен син башкаларга да күрсәт инде", - дип киңәш итте ул миңа". (Бу хәдис Әхмәд, Тирмизи, Нисагыйлар тарафыннан китерелә.)

Гүзәллекнең һәм чиксез әхлаклылыкның өлгесе булып имам Әбу Хәнифә мисалы яхшы үрнәкләрдән хисаплана. Гаять зур дәрәҗәле гыйлем кеше булуына да карамастан, ул үзенең тышкы кыяфәтенә дә зур игътибар биргән. Аның сакал җибәрүе, чиста, матур киемнәр, чалма, сандалилар киеп йөргәнлеге билгеле. Ул мөлаем тавышка, күркәм, матур сөйләмгә ия булган һәм еш кына хушбуй да сибеп йөргән. Хушбуйның таралган исеннән аның килгәнлеген белергә мөмкин булган.

Шулай итеп, Ислам күрсәтмәләре кешеләрне артыгын кыланмый, тәкәбберлеккә һәм исраф кылуга юл куймыйча, алтын урталык таләбен саклап, матур ки-

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Мәүла Колыйның дини-иляһияти карашлары

**XVI гасырда татарлар үз дәүләтчелекләрен югалта һәм шуның нәтиҗәсендә традицион сәяси һәм мәдәни институтлардан да колак кага. Иван Дүртенченең улы - патша Фёдор Иоаннович "Барлык мәчетләрне дә акрынлап ябарга, аларны тора-бара тәмам юк итәргә" дигән указ чыгара.**

Казан ханлыгының яшәүдән туктавы татар җәмгыяте тормышының табигый барышын боза. Дәүләтчелекне югалту халык өчен фаҗигагә әйләнә. Ул Мәскәүнең социаль-икътисади өстенлегенең тупас дини җәберләүләр белән бергә алып барылуы сәбәпле тагын да тирәнәя. 1555 елда Казанда бу җирлектәге халыкны, иң беренче чиратта - татарларны христиан диненә күчерү өчен архиепископ кафедрасы төзелә [Мухаметшин Р. Ислам в общественной и политической жизни татар и Татарстана в XX веке. - Казань: Татарское книжное издательство, 2005. - С. 22].

Бу шартларда ислам дине һәм мәдәнияте татарларның милли һәм рухи үзенчәлекләрен саклап калу җәһәтеннән халкыбызның төп таянычына әйләнә.

Татарларны руслаштыру һәм чукындыру сәясәте XVII-XVIII гасырларда да дәвам итә. Бу дәвердә дә татарларга (XVI гасырдагы кебек үк) үз милли бәйсезлекләре өчен көрәшергә туры килә. 50-60 нчы еллардагы баш күтәрүләр (ихтилал) вакытында татар җәмгыятенең феодаль югары даирәсе тулысынча диярлек юк ителү сәбәпле, каршылык күрсәтү хәрәкәтен рухи җитәкчеләр үз кулларына ала. Алар аннан соңгы чор халык күтәрелешләренең дә рухландыручылары булганнар [Адыгамов Р. Габдрахим Утыз-Имяни. - Казань: Фән, 2005. - С. 14]. Шундый зур халык күтәрелешләренең берсе Сәед (1681-1683 еллар) мулла җитәкчелегендә булган.

XVII-XVIII гасырларда татар җәмгыятендә суфичылык актуальләшә. Бу чорда татарларда суфичылыкның нәкышбәнди (икенче төрле - нәкшибәндия) юнәлеше (тарикате) киң тарала. Аның ватаны булып Урта Азия исәпләнә. Билгеле булганча, татар халкы дини гыйлем алыр өчен, нигездә, Урта Азиягә бара торган булган. Әлеге төбәк белән бәйләнешләр татарлар үз дәүләтчелекләрен югалткач та өзелми. Күп кенә татарлар Бохара, Сәмәрканд һ. б. Урта Азия дини үзәкләрендә укыган вакытта нәкышбәнди тарикате тарафдары булып киткән. Нәкышбәнди шәехләре (остазлары) татар шәкертләренә гаять зур йогынты ясаган. Шуңа да XVII-XVIII гасыр татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере күп очракта Урта Азия суфичылыгы йогынтысында үсеш ала.

Алда әйтеп кителгәнчә, XVII-XVIII гасырларда Идел буенда суфичылыкның ныклы таралыш алуының да үз мотивлары була, ул - халыкны турыдан-туры хәрби-сәяси каршылыклардан рухи-әхлакый кыйммәтләр буенча берләштерүгә күчерү зарурлыгы.

Нәкышбәнди тарикате үзенең исемен XIV гасыр кешесе Баһаведдин Нәкышбәндтән (1318-1389) ала. Ул Габделхалик Гиҗдувани формалаштырган "Тарик хаҗиган" (Хаҗигания) мистик тәгълиматын Әхмәд Ясәви тарикатеннән алынган нигезләмәләр һәм гамәли эшләр белән баета, алардан фикерләр өсти, нәкышбәнди мәзһәбенең оешма структураларын төзи.

Нәкышбәнди - карашлары буенча катгый сөнни булган 12 ана кардәшлеге (дини җәмгыять) мәзһәбенең берсе, аның рухи силсиләсе, ул бер яктан Әбу Бәкергә, ә икенче яктан Гали бине Әбу Талибка барып тоташа [Ислам. Энциклопедический словарь. - М.: Наука, 1991. - С. 187].

Баһаведдин хәзрәт аскетизмга, дөньяви эшләрдән баш тартуга кискен каршы чыга, хезмәткә һәм гыйлемгә өнди. Ул үзе дә менә дигән тукучы һәм металлны уеп рәсем ясаучы булган. Ни рәвешле эш алып барырга һәм хезмәт җимешләрең белән ничек итеп файдаланырга кирәк икәнлеген ул үз үрнәгендә күрсәтә алган. Аның шундый сүзләре бар:

*Күңел - сөеклегә (Аллаһка),*
*Кул - хезмәткә.*

Баһаведдин Нәкышбәнднең шундый яңалык кертүе аның дәвамчыларын барлыкка китерә. Күп санлы суфи дәрвишләр, үзләре үк җәмгыятьләр төзеп, Аллаһ юлында тырышлыклар күрсәтү һәм йолалар башкарудан тыш, үзләрен тәэмин итәр өчен хезмәт белән дә шөгыльләнә башлыйлар [Березиков Е. Святые ислама. - Казань: Татарское книжное издательство, 1996. - С. 125].

Нәкышбәнди тәгълиматының йогынтысы XVII-XVIII гасырларда яшәгән күп кенә суфи татар шагыйрьләренең иҗатында да тоемлана. Тарих фәннәре кандидаты Г.Идиятуллина, XVII-XVIII гасыр татар әдәбиятында суфичылык мотивларының көчәюен, Идел-Урал төбәге тарихының локаль үзенчәлеге булудан бигрәк, мөселман мәдәнияте үсешенең, Могол Һиндстаныннан алып Госман Төркиясенә кадәр булган барлык мөселман төбәкләре өчен дә хас булган гомуми үсеш чагылышы дип карарга тәкъдим итә [Идиятуллина Г. Духовно-религиозная атмосфера в Поволжье в XVII-XVIII вв. / Ислам в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки. - Казань: Мастер Лайн, 2001. - С. 176-201].

Татар суфи шагыйрьләре әсәрләренең теле халыкның сөйләм теленә бик якын торган. Күп кенә татарлар аларның әсәрләрен яттан белгән. Шул ук вакытта, алар төрле мәдрәсәләрдә дәреслек-кулланмалар итеп тә файдаланылган. Суфичылык шигърияте татар халкына колониаль чорда рухи мәсләкне югалтмаска, дөньяви вәсвәсәгә бирелмәскә ярдәм итә, рухи тынычлану тойгысы бирә, аны мәңгелек кыйммәтләргә юнәлтә.

Тикшерүчеләрнең билгеләве буенча, Идел буе һәм Урал алды XVIII гасырга кадәр, нәкышбәнди тарикатеннән тыш, әле һаман да ясәвия мәзһәбе йогынтысында була [Кемпер М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством / Пер. с немецкого. Серия "Зарубежное исламоведение". - Казань: РИУ, 2008. - С. 131; Об Ахмаде Йасави и Йасавийа. См.: Ходжа Ахмед Яссави. История г. Туркестан (Яссы). - Казань: Иман, 2003; Березиков Е. Святые ислама. - Казань: Татарское книжное издательство, 1996. - С. 54-69. Ди Уис Д. Йасавийа // Ислам на территории бывшей российской империи: Энциклопедический словарь. / Отв. ред. С.М. Прозоров. - Вып. 4. - М., 2003. - С. 35-38].

Татар суфичылык поэзиясенең XVII гасырның икенче яртысындагы иң күренекле вәкиле булып Мәүла Колый (шагыйрьнең тәхәллүсе шулай бирелә) исәпләнә. Аның иҗатында ясәвия һәм нәкшибәндия тарикатьләре традициясе чагылыш тапкан. Филология фәннәре докторы М.Әхмәтҗанов шагыйрьнең чын исемен Бәйрәмгали Колыев (Бимкә суфи яки Бимәк суфи) дип күрсәтә. Ул XVII гасыр урталарында Казан өязенең Чыты авылында (хәзер Татарстанның Питрәч районына керә. - авт.) туа. Казан мәдрәсәләренең берсендә укый. 1678 елда Казан өязенең төрле авылларындагы мөселманнар белән бергә Биләргә күченә. Гомеренең соңгы елларын ул хәзерге Лениногорск районының Иске Иштирәк авылында үткәрә. "Татар әдәбияты тарихы"нда 1678 елны Бимәк суфи Татарстанның хәзерге Минзәлә районындагы "Шыгай авылында галим Рабгузиның "Кыйссасел-әнбия" китабын күчереп алган" дип язылган. Шул белешмәләргә нигезләнеп, татар халкының атаклы галиме М.Әхмәтҗанов Мәүла Колый әле 1868 елда да исән булган дип расլый [Кара: Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000. - 270 б.]. Әмма халкыбызның икенче бер күренекле галиме Мәсгуд Гайнетдинов М.Әхмәтҗановның бу фикере белән килешми, Мәүла Колый иҗатында аның Бәйрәмгали Колыев биографиясенә туры килүче фактлар юк дип исәпли [Кара: Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004. - 319 б.]. Мәүла Колый барыннан да бигрәк үзенең хикмәтләре белән билгеле [Хикмәт (гарәпчәдән зирәк гыйбарә, фәлсәфә; философия; мәкаль; сер дигәнне аңлата) - шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында да дидактик жанр. Хикмәтләргә кыскалык, афоризмлык, гыйбрәтлелек, фикер тирәнлеге, аңлаешлылык хас. Хикмәтләрнең күбесендә әхлакый-фәлсәфи проблемалар чагылыш таба]. Татар әдәбияты белгече Г.Сәгъди: "Алар формаль һәм стиль ягыннан Әхмәд Ясәви (XII йөз) яки аның традицияләрен дәвам итүче башка суфилар хикмәтләренә барып тоташалар", - дип яза [Кемпер М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством / Пер. с немецкого. Серия "Зарубежное исламоведение". - Казань: РИУ, 2008. - С. 134]. Мәүла Колый күп кенә хикмәтләрендә (без бу мәкаләбездә Мәүла Колыйның түбәндәге җыентыкта нәшер ителгән хикмәтләрен файдаландык: Колый М. Хикмәтләр / Төзүче, кереш сүз авторы М.Гайнетдин. - Казан: Иман, 2001. - 136 б.) Әхмәд Ясәвинең шәкерте Сөләйман Бакырганины (1186 елны вафат) искә ала. Мәүла Колый үзе нәкышбәнди тарикате тарафдары була. Бу турыда аның Мамай мулла остазы турындагы белешмәләр дәлил булып тора. Ул Казан шәһәрендә туган һәм Урта Азия шәехләрендә белем алган [Абилов Ш. Шагыйрьнең исеме Мәүла Колыймы, әллә Меллаголмы? // Совет әдәбияты. - 1958. - № 11. - Б. 108]. Мәүла Колый үзенең 20 нче хикмәтендә аның пире (остазы) Мәхзүми Әгъзам (1464-1542) нәселеннән булуы турында хәбәр итә:

*Пиремнең Мәхзүми Әгъзам бабалары,*

*Андин мәдәд теләр җиһан падишаһлары.*

Шагыйрь үз остазының яхшы сыйфатларын санап: "Ул Сәмәркандта туган иде, төрле җирләрдән - Болгардан, Казаннан чыккан күп кенә кешеләр аның мөридләре иделәр", - дип искә ала. Сүз Урта Азиянең атаклы сәясәт һәм дин эшлеклесе Мәхзүми Әгъзам турында бара. Аның хезмәтләрендә нәкышбәнди мәзһәбенең сәяси эшчәнлеге турындагы нигезләмәләр аеруча зур тулылыкта үсеш ала. Бу сәяси эшчәнлек, Мәхмүд Әгъзам фикере буенча, аерым бер миссия - тарикать җитәкчесе хакимнәренең явызлык кылмавы һәм шәригать буенча хакимлек итүләре өчен җаваплылык. Мәхзүми Әгъзам һәм аның нәселе, дәвамчылары Урта Азия суфичылыгы тарихында гадәттән тыш роль уйный, алар нигезләгән нәкшибәндия-дәһбидия традициясе озак вакытлар бу төбәктә әйдәп баручы юнәлеш булып кала [Ибатуллина Г. Развитие татарской общественной и богословской мысли в XVIII веке // Восстание под предводительством Батырши и общественно-культурная ситуация в татарском обществе в XVIII в. Материалы научно-практической конференции (17 мая 2005 г., г. Казань). - Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2007. - С. 21]. Без билгеле бер ышанычлылык белән Мәүла Колый нәкшибәндия-дәһбидия суфичылык тарикате идеяләре тарафдары булган дип әйтә алабыз.

**(Дәвамы бар.)**

***Нияз хәзрәт САБИРОВ, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы, Казан ислам колледжы директоры урынбасары***



# Кая тәгәрибез?

**Мәктәп еллары куанычлы да, күңелле дә, тынгысыз да. Моны XI сыйныфта гына аңлыйсың икән. Мәктәп еллары һәр кеше тормышында зур урын алып тора, чөнки ул еллар - балачак еллары. Ә балачак елларын әле беркемнең дә читләтеп үтә алганы юк. Шуның белән бергә ул еллар - кешенең шәхес буларак формалашкан еллары да. Олыгая барган саен, ул елларның һәр мизгеле үзәкләрне өзеп хәтерләрдә кабат яңарачак әле.**

Мәктәптә башлангыч сыйныфларда укыганда киң күңелле укытучым Нурия апаның, елмаеп: "Хәерле көн, балалар. Әйдәгез, дәресне башлап җибәрик", - дип эндәшүләре әле дә истә. Гадел, түземле, тыныч һәм ягымлы булуы белән укучыларны үзенә тартып торучы якын дус иде ул. Уңышларыбызга сөенеп, кайгыларыбызны уртаклаша, хәлебезгә керә иде.

Кызганыч, хәзер укучыларның укытучыларга карата мөнәсәбәте без укыган еллардагы кебек түгел. Бүгенге укучы хөрмәт дигән төшенчәне оныта бара, ахрысы. Укучылар, гомумән, артыгын кылана: укытучы белән телләшә, киресен сөйли, ачуланыша, дәресләрдә киреләнеп, холык күрсәтеп утыра. Мондый күренеш көннән-көн ешая, чөнки гаиләдә ата-ана баласында хөрмәт хисләре тәрбияләми. Балалар гаиләнең көзгесе дип зерәгә генә әйтмиләр бит. Шәхси үзенчәлекләре булуга да карамастан, балаларда гаиләнең холкы чагыла.

Бала гаилә тормышы аша дөнья белән таныша, яхшыны, начарны, тәрбиясезлекне күрә. Балалар үсеп җиткәнче, вакытларының күп өлешен ата-аналары янында уздырган бер чорда, аларга урамда ничек тәртипле булырга, табигатьне ничек сакларга, авыруларга, картларга ничек ярдәм итәргә кирәклеге турыдан-туры өйрәтелергә тиеш.

Күптән түгел сеңелемне мәктәптән каршы алырга бардым. Коридорда көтеп торганда шундый күренешкә тап булдым. Йөгереп уйнаучы укучыга өлкән яшьтәге укытучы кисәтү ясады, мәктәптә йөгереп йөрергә ярамаганлыгын аңлатты. Укучыга кисәтү ошамады, ул укытучының сүзләрен колагына да элмичә, телләшеп, ачу белән узып китте. Әйтерсең үз яшьтәше белән сөйләшәмени, киткәндә хәтта борын астыннан нәрсәдер мыгырданды да.

Мондый күренешнең җәмгыятебездә ешаюы, яшь буынның олыны олы, кечене кече итеп күрә белмәве кешелек кыйммәтләренең түбәнгә тәгәрәве түгелмени?

**Иркә САДРИЕВА**

# Г.ИСХАКЫЙ ҺӘМ Г.ТУКАЙ
## әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемалары

***(Ахыры. Башы газетабызның 22 февраль, 1 март саннарында.)***

Аллага дога кылу күренеше Тукайның "Туган тел", "Йокы алдыннан" шигырьләрендә дә бик тәэсирле итеп чагылдырыла.

Кеше үз күңеленә урын таба алмаганда, кайгы-хәсрәткә дучар булганда яки туры юл эзләгәндә дә Аллага мөрәҗәгать итә: Аллаһның изге сүзе - Коръәнне укый, шуның белән җанын тынычландыра, рухи азык таба. Тукай да бөтен җан тынычлыгын Коръән укудан табуы турында "Тәэссер", "Китап" кебек шигырьләрдә бәян итә.

*Гомернең читен, җайсыз,*
*уңгайсыз бер минутында,*
*Әгәр янсам кайгы вә хәсрәтнең*
*мин утында,*
*Укыйм тиз-тиз күңелдән бер*
*гаҗаиб сүрә Коръәннән, -*
*Газаплар мәгънәви бер кул илән*
*алынадыр җаннан.*

Билгеле булганча, һәр мөселман өчен белем алу фарыз. Татарлар да мәгърифәтле, аң-белемле булуга, балаларда яшьтән үк белем алуга мәхәббәт тәрбияләүгә аеруча зур игътибар биргәннәр. Тукай да, чын педагог буларак, балаларга белем алуның, тырышып укуның зарурилыгын күп кенә шигырьләрендә дәлилли. "Ата илә бала" шигырендә гаилә башлыгы буларак, ата үз баласына файдалы киңәшләр бирә, аны рухи яктан дөрес тәрбияләүгә омтыла:

*Яз, газиз угълым: кара*
*тактаны сыз акбур белән!*
*Һәм кара күңелеңне ялт иттер*
*сызып ак нур белән!*
*Өч наданга алмашынмас - бер*
*язу белгән кеше;*
*Мәгърифәт эстәр, иренмәс*
*һич - кеше булган кеше.*

"Бәхетле бала" шигырендә Тукай бәхет төшенчәсен белем төшенчәсе белән тыгыз бәйли:

*Бәхетле шул баладыр, кайсы*
*дәрсенә күңел бирсә,*
*Мөгаллимне олуг күрсә,*
*белергә кушканын белсә.*
*Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,*
*Уенга салмаса ихлас - менә бәхете аның шунда.*

Биредә шагыйрь, белем алуның фазыйләтен ассызыклавы белән бергә, белем алу әдәпләрен дә күрсәтә. Бүген укытучыларга мөнәсәбәт тискәре булган җәмгыятебездә Тукай шигыре тагын да актуальләшә.

"Ике юл" шигырендә дә гыйлем алуның өстенлеге дәлилләнә:

*Ике юл бар бу дөньяда:*
*берсе будыр - бәхет эстәү;*
*Икенче шул: гыйлем гыйшкында*
*булмак - мәгърифәт эстәү.*
*Синең кулдан теләрсең -*
*мәгърифәтле бул, бәхетсез бул;*
*Вә яки бик бәхетле бул, ишәк бул,*
*мәгърифәтсез бул.*

Биредә ишәк кебек, йә булмаса, бер кайгысыз рәхәт гомер кичереп, матур киенеп, тәмле ашап, күп йоклап яшәү беренче карашка бәхет кебек тоелса да, чынлыкта бәхетсезлек икәнлеге аңлашыла. Ә авырлыкларны сабырлык белән кичереп гыйлем эстәү бәхеткә китерә.

Чын бәхеткә ирешү өчен, гыйлем алу белән бергә, хезмәт итүнең дә мөһимлеген Тукай сабыйларга "Эш" шигырендә үтемле аңлатып бирә:

*Тынма, эшлә, и сабый!*
*Бел, Тәңредән эшләргә - көн,*
*Эшләп аргачтан бирелгәндер*
*тыныч йокларга төн.*
*Иртә торгач та язарга,*
*дәрсең укырга тотын;*
*Тынма, эшлә, торма тик,*
*тынсаң тынарсың җомга көн.*

"Эшкә өндәү" шигыре дә бу фикерне дәвам итә. Мәңгелек бәхеткә ирешү, үзеңнән соң күркәм эз калдыру өчен фидакарь хезмәт куюның зарурилыгын дәлилли Тукай.

Шулай итеп, Г.Исхакый да, Г.Тукай да халык күңелендә мәңге яшәячәк, тәрбияви әһәмияткә ия булган әсәрләр тудырып, гаделлек, тынычлык, югары әхлак, нык иманлы нәсел дәвамчыларының булуы, милләт язмышы кебек мәңгелек проблемаларны күтәреп чыгалар һәм әсәр укучыларны да шул хакта уйлануга этәрәләр.

**Ильмира НИЗАМОВА**

# "Сабыйга" акциясендә катнашыйк!

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Татар радиосы" һәм Бөгелмә мөхтәсибәте белән берлектә, әти-әниләре ташлаган сабыйларга подгузник, пелёнка кебек кирәк-яраклар җыю максатыннан, "Сабыйга" дип аталган хәйрия акциясе уздыра.**

Сабыйлар Бөгелмә районы балалар хастаханәсе каршында урнашкан "социаль койкалар"да сәламәтләндерү һәм тернәкләндерү курслары үтә. Мондый курсларны алар 30 көн эчендә үтеп бетәргә тиеш, ләкин тормыш күрсәткәнчә, әлеге вакыт аралыгында гына моңа ирешеп булмый, шунлыктан дәвалану берничә айга сузыла. Балаларны урнаштыру буенча аларның хокукларын кайгырту (опека) бүлеге шөгыльләнә, алар балага яңа әти-әни таба яки аны якындагы балалар йортына урнаштыру җаен карый. Уртача алганда, ай дәвамында балаларның "социаль койкалар"ыннан дистәгә якын сабый уза. Әлеге сабыйлар үзләренең әти-әниләре тарафыннан кире кагылсалар да, җир йөзендә ярдәм кулы сузарга әзер торучы мәрхәмәтле кешеләр аз түгел. Барчагызны да сабыйларның гомеренә битараф калмаска чакырабыз.

Акция 1 марттан 31 мартка кадәр уза. Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр бала карау әйберләрен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә китерә ала. Адресыбыз: Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт, хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге. Элемтә өчен телефон: +7 (843) 264-61-58 (Гөлнара Садыйкова).



# ИГЪТИБАР!
## МӨФТИ БУЛЫРГА ТЕЛӘҮЧЕЛӘРГӘ КУЕЛГАН ТАЛӘПЛӘР

*2013 елның 14 мартына, кичке сәгать бишкә (17.00) кадәр Мөфти вазифасына кандидатлардан документлар кабул ителә.*

Мөфтилеккә кандидат булырга теләүчеләр гариза язарга тиеш.

**Гариза түбәндәгечә языла:**

Пленум утырышында _____________ вазифасына рәсми кандидат буларак карау һәм раслау өчен документларны кабул итүегезне сорыйм.

**Гаризадан тыш, түбәндәге документлар сорала:**

- паспортның ксерокүчермәсе;
- татар һәм рус телләрендә язылган автобиография (кулдан язылырга тиеш);
- белем алуны раслаучы документларның ксерокүчермәсе;
- хезмәт кенәгәсенең ксерокүчермәсе.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Уставының 7.2 пункты нигезендә, мөфтилеккә кандидат дини һәм дөньяви белемле, гадел, намуслы булырга тиеш. Шулай ук бернинди дә сәяси партияләрдә тормавы, хөкемгә тартылмаган һәм начар гамәлләр кылмаган булуы шарт. Моннан тыш, дини җитәкчелек урынында иң киме 5 ел дәвамында өзлексез эшләве таләп ителә.



**Мөфтилеккә рәсми кандидатлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Пленумында раслана.**

# РУХИ МАТУРЛЫК ҺӘМ ТЫШКЫ МАТУРЛЫК

***(Ахыры. Башы 1,2 нче биттә.)***

емнәр киеп йөрүне тыймый гына түгел, хәтта хуплый да. Бу турыда Коръәни-Кәримдә дә әйтелгән (мәгънәсе): "Әй, Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда һәрвакыт пакь киемнәр киегез; ашагыз, эчегез, ләкин (артыгын) исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми" ("Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре"ннән, "Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 31 нче аяте).

Исламда хатын-кыз матурлыгына да яхшы мөнәсәбәт урнашкан. Ул энҗе бөртеге кебек, чит карашларга ташланмыйча, бары тик өйдә генә үзенең бар балкышы һәм күркәмлеге белән тормыш иптәшенең күзләрен назлар өчен ачылырга тиешле. Иң яхшы киемнәрең белән үзеңнең кадереңне белеп, ягымлы елмаю, күтәренке күңел белән иреңне каршы алу, күркәм, матур булып күренү - Аллаһы Тәгаләнең мөслимәләргә йөкләгән куанычлы вазифаларыннан санала.

Гомерлек юлдаш сайлаганда югарыда телгә алынган матурлыкның кайсысына әһәмият бирә икән безнең укучыларыбыз? Кызыксынып китеп, шул хакта сораштыру үткәрергә булдым. Җавапларын сезгә дә тәкъдим итәм.

***Мансур хәзрәт Хитматов:*** "Миңа калса, тормыш итәр өчен кешенең эчке матурлыгына карарга кирәк".

***Илнур (студент):*** "Кешенең эчке матурлыгына игътибар итәм. Чөнки тышкы матурлык үз вакыты белән генә, ә кешенең эчке матурлыгы озак саклана.Тышкы матурлыкка гына игътибар иткән кешене мин сукыр дип саныйм. Эчке матурлык ул - зур бәхет".

***Илнар (оператор):*** "Матурлык дигәч татар халык мәкаләсе искә төшә: "Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк". Димәк, кешенең күңеле матур булырга тиеш".

Шулай итеп, шуны истә тотсак иде: ислам дине үз-үзеңне пөхтә тотарга, хәлеңә карап киенергә өнди. Затлы киемнәр белән масаеп, кыланып йөрү мөселманлык сыйфаты түгел. Монда да чама хисен югалтмасак иде.

**Ләйсән ГОБӘЙДУЛЛИНА**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (179) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35393.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 7 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллануда сакланыгыз!**